# РЕЗЕДА, БӘГЫРЬКӘЕМ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

Тугайларда ал чәчәкләр җыясыңмы?
Тугайларны су назлап дулкынлана.
Айга карап күз нурларын коясыңмы?
Безне ай эзләп, тын алмый, моңлана.

**Кушымта:**

Резеда, бәгырькәем! Ник килмисең, гөлкәем?
Күптәннән сүнгән инде шәфәкъ нуры.
Әйтче, нигә көн буе күңелең синең боек?
Моңланасың нигә? Әйт миңа туры!

Резеда, бәгырькәем! Минем назлы гөлкәем!
Сайрый, сайрый арыган сандугачлар.
Бирче, иркәм, кулыңны! Аччы миңа сереңне!
Сердәш булсын безгә тәүге йолдызлар!

Сине сагынып, дулкын ярны кыйный бугай,
Уйчан таллар тик сине уйлый бугай.
Нигә качтың, кая качтың соң син шулай?
Яшерде эзләреңне куе тугай.

**Кушымта.**

Яратам мин сине генә, сизәсеңме?
Кумассың бит, яныңа үзем килсәм?
“Башканы сөям бит шул!” - дип әйтмәссеңме,
Саф йөрәгемне сиңа бүләк итсәм?

**Кушымта.**

**Резеда, душа моя**

Песня посвящена девушкам по имени Резеда.

Резеда, душа моя! Почему ты не приходишь, цветок мой? Почему грустишь и печалишься? Дай мне руку! Открой мне свое сердце! Пусть нашу тайну узнают звёзды!